КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 август г.Казань № 707

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасын оештыру турында» 2013 ел, 27 август, 603 нче карары белән расланган «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасы хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасын оештыру турында» 2013 ел, 27 август, 603 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 июнь, 419 нчы; 2014 ел, 16 декабрь, 990 нчы; 2015 ел, 2 апрель, 207 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасы хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә:

«Хисаплар бер тапкырга һәм күпдәрәҗәлегә бүленә. Күпдәрәҗәле – үзара темасы, вакыттан вакытка кабатлануы яки мәгълүматлар тапшыру вакытлары белән берләшкән ике яки аңарга керә торган берничә бер тапкыр хисаплардан торган хисап. Бер тапкыр хисапларны берләштерүче хисап төп була, аңарга керә торган бер тапкыр хисаплар ярдәмче хисаплар дип атала. Күпдәрәҗәле хисап мәгълүматның ачыклыгын яхшырту максатында төзелә;»;

2.4 пунктта:

дүртенче абзацка «, мәгълүматларны актуальләштерү интервалын билгеләп, хисапны бастырып чыгаруның регламет вакытларын билгели. Күпдәрәҗәле хисапларны бастырып чыгару вакыты төп хисапны бастырып чыгару датасы буенча билгеләнә» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Ачык һәм һәркем файдалана алырлык мәгълүматларны үз эченә алган хисап ачык мәгълүматлар формасында мәгълүмат бирүне автомат рәвештә күздә тота;»;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин